Рәшит ЯКУПОВ

# САРАБИККОЛ

## (Әби авылы)



## *Кулланылган чыганаклар:*


1. Татарстан тарихы. 1995.
2. Җ. Рәхимов. «Шөгер төбәге хәзинәләр чишмәсе».
3. Әнвәр Шәрипов «Габдерәхим Утыз Имәни». 1986.
4. Ө. Г. Мөхәммәтҗанов «Әхметҗан Бине Шәмсетдин Аль-Тубыли».
5. Татарстан дәүләт милли архивы материаллары.
6. Россия фәннәр академиясе Уфа фәнни үзәге тарих институты материаллары.
7. Сарабиккол авылы кешеләре истәлекләре. 1952–2009 ел.


## *Китапны хәзерләүдә булыштылар.*

*Фәйрузов Р. С.* – архив материалларын җыешты, финанс ярдәм бирде.
*Якупова Г. Г.* – тарихи материаллар җыюда.
*Якупов А. Ф.* – компьютер белән эшләде.
*Гатина С. Ә.* – компьютер белән эшләде.


**Якупов Р.**

Сарабиккол (Әби авылы). Чаллы, ҖЧЖ «Диамант», 2011. 618 бит.

Мөхәррире *Рәшит Бәшәр*
Техник мөхәррире *Илшат Фәррахов*

Форматы 60x84 $^{1}/_{16}$. Күләме 39,0 басма табак. Офсет кәгазе.
Тиражы 500 данә. Заказ

ҖЧЖ «Диамант».
423802, ТР, Чаллы шәһәре, Үзәк урам, 72.
Тел. (8552) 705-145.

## Таулар

**Базар тавы.** Бу тау авыл белән янәшә, көнбатыш яклап урнашкан. Аның килеп чыгышы турында халык арасында ике караш яши.

1. Бу тауда базар мәйданы булган. Тирә-як авыллардан килгән кешеләр монда сату-алу иткәннәр. Соңрак, Куак руслары аның өчен зур тавыш чыгарып, базарны Куакка күчерткәннәр.

2. Кешеләр, шушы тауга менеп, Шушма крепостена (Шушменкага) базарга бара торган булганнар (14 километрлы юл булган ул). Олы юл Балталы күпере аркылы үткән. Ул күпер 1938–1940 елларда да бар иде әле.

**Мөгәҗи тавы.** Төньяклап авыл терәлеп утырган тау, аның өстеннән Федотовка авылына бара торган юл үтә. Атамасының килеп чыгу вариантлары:

1. Тауда (Керәшен тыкрыгында) кибет булган («мөгәҗи» сүзе «магазин» сүзеннән килеп чыккан). Кешеләр шунда тоз, шырпы, керосин, сабын сатып алыр өчен барган. Кибетнең төгәл урыны билгесез.

2. Керәшен тыкрыгыннан әз генә астарак, уң якта зират өстендә ашлык саклау өчен амбар-склад булган. Янгыннар еш чыгып тору сәбәпле, уттан зыян күргән кешеләр чәчүлек орлыгын шуннан алган, чөнки бар запас шунда гына сакланган. Амбар-склад ике катлы итеп төзелгән, беренче каты җир астында булган. Бу вариант Мостафин Хәтиф һәм Сафин Шәһит истәлекләреннән алынды.

**Әхмәт тавы.** Авылдан көнбатыштарак, юнәлеше – төньяк-көнчыгышка таба. Тау берничә өлештән тора һәм берничә исем белән атап йөртелә.

**Шандор (Шантур) тавы.** Әхмәт тавының бер өлеше. 18 нче гасыр ахырларында нефть эзләүче эшкуар, Америка промышленнигы Ласло Ф.Шандор Шушма елгасы буенда тикшеренүләр үткәргән, нефть эзләгән. Ул хәзерге Шандор тавы итәгендә 204 метр тирәнлеккә скважина (торба) төшерә, алга таба да казу эшләрен оештыра. Авыл халкы өчен бу исә эш чыганагы була, нәтиҗәдә күп кешеләр ялланып, аңа хезмәт итә башлый. Шулар арасында Шаһи исемле кеше дә эшли, ул Шандорның баш хезмәтчесенә әйләнә. Аның белән бәйле бер кызык вакыйга турында да сөйлиләр.

Татар халкының күркәм бәйрәмнәре Шандорның күңеленә хуш килә, ул аларны яратып карый торган була. Шулай бер елны Сарабиккол авылы Сабан туенда Милли көрәш буенча баш батырны билгели алмыйлар. Шунда Шандор: «Шаһины алып килегез, ул барысын да җиңәчәк!» – дигән. Шаһины читән арбага утыртып алып киләләр. Чыннан да, көрәштә катнашып, Шаһи җиңүче булып чыга, алай гына да түгел, ул хәтта Шандорның үзен дә баш өстеннән генә җиргә алып сала! Җиңелгән промышленник баш батырга, җиңү бүләге итеп, 20 сум акча бирә. 20 сум ул заман өчен бик зур акча булган. Шаһи ул акчага ике өлешле таш пулат салдыра, хәтта хаҗга да барып кайта



**Ташкичү таулары.**

(шуннан соң аны авылда «Шаһи хаҗи» дип йөртә башлыйлар).

Ул салдырган пулатта склад, кибет, келәт һәм башка төрле бүлмәләр була. Һәм ул шундый ныклы корылма булган ки, аның корылмалары хәзерге көнгә кадәр (!) сакланган.

Шантур тавыннан төньяктарак **Әхмәт тавы** башлана. Атамасының килеп чыгуы турында вариантлар:

1) Тау итәгендә Әхмәт исемле кеше яшәгән, тауның атамасы да шуннан калган.

2) Сарабикколга беренче булып килгән төркем арасында бер кешенең аты дулап, җайдагы егылып үлә. Шул җайдакның исеме белән шушы тау атала башлый. Шуннан бу тау Әхмәт тавы булып кала.

Әхмәт тавының дәвамы **Бурлы тау** дип атала. Бу тауда известь ташы, мәрмәр запаслары өстә үк ята. Кешеләр аннан известьташ җыеп, яндырып, акбур ясаганнар, аны тирә-як авылларга алып барып сатканнар. Бурлы тау (акбурлы тау) исеме әнә шуннан калган. Ул вакытларда иң күп акбур сатучы кеше Әгъзәм Баһаветдинов булган.

Бурлы таудан төньяктарак **Бәдретдин тавы** бар. Атамасының кайдан килеп чыкканлыгы билгесез. Аннан соң, бу тауларның дәвамы буларак, **Өч имчәкле тау** сузыла (өч тармаклы булганга, аңа шундый исем бирелгән).

**Пожар тавы.** Авыл уртасындагы иң биек урын. Аның өстеннән караганда, авыл бик ачык күренә. Элек, янгыннар еш чыгып тору сәбәпле, авыл халкы шушы тау өстенә биек каланча (вышка) төзеп куйган, ә янгынчылар ут булу-булмавын шуның башыннан күзәткәннәр.

Каланчаның биеклеге – 5–6 метр чамасы. Насослар һәм пожар атлары өчен сарай, кизү торучылар өчен аерым бүлмә (дежурлар бүлмәсе) төзеп куелган. Бу тауның

бер өлеше **«Каһарман тавы»** дип атала. Аннан Тегермән чишмәсе башлана.

**Суд тавы.** Авылдан көньяктарак әлләни биек булмаган бер урын бар. Әлеге калкулыктан көньякка таба олы юл үткән, шул юлдан кешеләр волость судына бара торган булган. Волость суды Чытырлы авылында урнашкан. Суд тавы, Түш исемнәре әнә шуннан калган.

**Бәләкәй бүләк тавы.** Колхозлашу чорларында колхозга кермәгән аерым хуҗалык кешеләренә кечкенә-кечкенә җир кишәрлекләре бүленеп бирелгән. Ул участоклар хәзерге **Өчаяк тавы** астында урнашкан, алар бик кечкенә кишәрлекләрдән торган. Җирләре бик начар булган, аерым хуҗалык кешеләре бу җирләрне эшкәртеп, иген иккән һәм аны «бәләкәй бүләк» дип атап йөрткән. Тауның исеме шуннан калган.

## Тугайлар һәм болыннар

Сарабиккол авылының данлыклы Тугае көньяк-көнбатыш юнәлештә. Шушма бассейнындагы зур болын. Элек бу тугайның күпчелек өлеше шомырт агачлары һәм гөлҗимеш куаклары белән капланган булган. 1945–1947 елларда агач-куакларны төпләп, болынны киңәйттеләр. Язлар җитү белән Тугайны кар сулары сугара. Берничә ел дәвамында ясалма сугарылды. Хәзерге вакытта бу тугай культуралы көтүлек ролен башкара.

**Балталы тугае.** Ул көнбатышка таба 3–4 километр ераклыкта урнашкан. Уртасыннан кечкенә генә Балталы инеше ага. Ул Мукшы хуторы тирәсеннән башланып, Шушмага коя. Кислобрак басуына (туфрагы әче булганга, аны шулай атыйлар) чыгу өчен волость администрациясе шул елга аша күпер салдыра, ул күпер 1943 елга хәтле

сакланган.

Элек бу тугай авыл халкы терлекләре өчен печәнлек булып хезмәт иткән, әмма хәзерге көндә ул ташландык хәлдә, сазланган.

**Михәйлә тугае.** Бу тугай Сәйлән чокырыннан көнбатышка таба урнашкан. Атамасының килеп чыгуы турындагы вариантлар:

1. Балыкчы Михаил шунда балык тотканда батып үлә. Тугайның исеме шуннан кала.

2. Чуваш Михаил шунда яшәгән, балык тотып, шуны сатып көн күргән. Михаил исеме шуннан калган.

**Монасыйп тугае.** Кызыльярдан көнчыгышка таба җәйрәп яткан зур болын. Тау буенда күле бар. Яз җиткән саен шул күлгә җылы яклардан кайтучы күчмә кошлар төшә. Атамасының килеп чыгуы турындагы вариантлар:

1. Бирердә Монасыйп исемле кешенең пай җире булып, ел саен ул шунда печән чаба торган булган.

2. Шул тугай күле янында Монасыйпның (Монасыйп – Ишанлы улы Әхмәр малае) өе булган, гомер буе шунда яшәп, шунда бакыйлыкка күчкән.

**Ишалгы тугае.** Элек Сарабиккол кырлары территориясе Кармалка авылының кырыеннан ук үткән. Мордвалар моңа каршы ризасызлык белдергәннәр, алар күбрәк мәйданда җир таләп иткәннәр. Шул максат белән Кармалка авылы халкы землемер – җир үлчәүче кеше чакырткannnар. Землемер үзе христиан дине вәкиле буларак, әлбәттә, мукшы халкын яклаган. Сарабиккол – Кармалка җирләрен бүлү вакыйгасын күзәтергә ике яктан да бик күп кеше җыелган, алар арасында безнең авыл байлары Ишалый белән Рәшит тә булган. Мукшылар үзләренә яхшырак җирләрне калдыру теләге белән Рәшит байга яшерен рәвештә генә бер түбәтәй тулы бакыр ак-

ча тәкъдим итәләр һәм ул, акчаны алып, мукшылар яклы булып кала. Ә Ишалый бай ризасызлык белдерә. Шул вакытта мукшыларның берсе: «Ишай, ты не мешай. Рашит дело решит», – ди. Шуннан соң әлеге елга буендагы бу җирләр Ишалый тугае (Ишалгы, Ишанлы тугае) дип атала башлый.

Соңрак бу болынның бер өлешенә алмагачлар утыртып, алма бакчасы ясаганнар. Ул бакча уңыш та бирә башлый. Ләкин 1941 елгы каты салкыннарда алмагачлар өши һәм корый. Гомумән, сугыш елларында бакчага игътибар бик нык кими. Хәзерге көндә бу тугайда кыргыйлашкан 3–4 төп алмагач кына үсеп утыра, шулай да авыл халкы бу урынны «алма бакчасы» дип йөртүен дәвам итә.

**Кысык.** Авылдан төньякта урнашкан. Ул Әхмәт тавының дәвамы һәм урман тоташкан урын (бер-берсенә кысылып киләләр). Тау өсте урман белән капланган. Хәзер инде урман сирәкләнгән, агачлар әз калган.

**Җәйләү.** Урман-тау кысыгыннан өскә таба юл менә. Бу юл Җәйләүгә барып тоташа. Ярлы халыкның җәйләре шунда пай җирләрен эшкәртеп, иген игеп узган. Алар: «Җәйләүләрдә без җәйләдек, якты көннәр күрмәдек», – дип җырлый торган булганнар. Җәйләү урманнарында качкыннар да яшәгән, алар җирле халыктан ярдәм сорарга килгәләгәннәр. Чикләвек җыярга баручылар качкыннарны еш күргән.

**Участка яки Учаска** («участок» сүзеннән). Авылдан көнбатышка таба 4–5 километр ераклыкта урнашкан бер җир участогы. Лагерька юлы буйлары элек бояр җирләре булган. Ә безнең авыл халкының бер өлеше бу боярларга ел саен эшкә ялланган. Акылга җиңел боярларның берсен «тиле бояр» дип йөрткәннәр. Шуңа бу җирләр **«Тиле бояр җирләре»** дип аталган.

**Стулла** («стойло» сүзеннән). Шайтан чокыры итәге, Даут Габбазов бакчасы башындагы чишмәле урын, басу. Бу урын Сарабиккол халкының һөнәр участогы булган. Монда һөнәрчеләрнең чана табаны бөгү, тәгәрмәч ясау станоклары торган. Шунда ук каен тузыннан сумала кайнатканнар, димәк, бу тау итәкләрендә кайчандыр каен урманнары да шаулап утырган. Шунда ук янәшәдә Шушма елгасы да агып яткан, хәзер исә аның биредә бүленеп калган калдык күлләре генә сакланган, язгы ташу вакытларында алар су белән тула.

**Тирәнкул (Тирәнкүл).** Авылның көнчыгыш ягындагы икенче тирән чокыр. Аның башында язгы кар сулары белән тула торган өч батынкы урын бар. Агачлар арасындагы су хәтта җәйге кызу көннәрдә дә кипми. Урман җәнлекләре су эчәргә дип шунда килә. Миңа бу күлләрнең берсен генә күрү насыйп булды, җәй уртасы булуга карамастан, суы күп иде.

Элекке заманнарда Тирәнкүл башында чыбыктан үрелгән шактый иркен сарайсыман бер корылма булган. Анда урланган малларны (атлар, сыерлар, сарыклар һ.б.) яшереп асраганнар. (Рәхимә Авшированың әнисе Хафизә истәлекләреннән).

**Ташкичү.** Авылның көньяк өлешендә, Мукшы елгасының сул ягында урнашкан таулар төркеме. Анда элеккеге вакытлардан алып, хәзерге көннәргә кадәр таш кисү эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Кискән ташларны төзелеш өчен файдаланганнар: юлларга түшәгәннәр, йорт нигезләренә куйганнар, таш келәтләр салганнар һ.б. Исеме «таш кисү» сүзеннән алынган, Ташкичү дип атала.

**Әкүлчә** («околица» сүзеннән). Бу – авылны аерып тора торган киртәләр тезмәсе яки божрасы. Авыл, басуга мал-туар чыкмасын өчен дип, махсус киртәләр белән

уратып алынган урын. Киртәне тоту өчен һәр гаилә хуҗалыгына үз участогы беркетелгән булган. Әкүлчәгә өлкән яшьтәге берничә карт чиратлашып күзәтчелек иткән. Җимерелгән участокларны алар үзләре төзәтмәгән, ә шул участок өчен җаваплы кешене «чижи»га чакыртып (авыл Советы кебек), тиешле чаралар күргәннәр: я таяк, я чыбык белән суктырганнар. (Әлеге мәгълүматлар Хәтиф Мостафин истәлекләреннән алынды).

Авыл башында, тыкрык башларында әкүлчә капкалары булган, аларга да беркетелгән аерым җаваплы кешеләр күзәтчелек итеп торган. Капкалар Кирлегәч очында, Куак очында, Гата Рәхимәләре тыкрыгында, М.Кармалка ягында һәм Базар тавында булган. Базар тавындагы үз куышында капкага Шәкүр карт күзәтчелек иткән. Җәйләр үтеп, уңыш җыю вакыты җиткәч, көлтә төягән олаулар авылга кергәндә, капка төбен саклаучыларга һәр олаудан берәр көлтә биреп калдыра торган булганнар. Шулай итеп җыелган көлтәләрне капка каравылчылары кибәнгә (омёт) салганнар.

Әкүлчә һәм җир пайларының исәбен алып бара торган кеше Әбделгани исемле булган. Аның йорты Керәшен тыкрыгында торган. Ул бернинди язусыз-нисез дә кемнең пае кайсы җирдә, кемнеке белән янәшә икәнен хәтерендә ачык саклаган (Хәтиф Мостафин, Мәхмүҗан Шаһиева истәлекләреннән).

Әбделгани картның Хәйдәр исемле бер улы (Гамбәрия Гыйлалованың ире), хәзер Җәлил шәһәрендә яши.

## Авылның нигезләнүе

Сарабиккол авылының тарихи тамырлары шактый ук борынгы чорларга барып тоташа. Бу авыл тарихына бәйле байтак чыганаклар бар. Җәмит Рәхимовның «Шөгер төбәге – хәзинәләр чишмәсе», Харис Гомәровның «Авылым, авылдашларым» китаплары, Өлфәт Мөхәммәтҗанов, Әхмәтҗан бине Шәмсетдин әл Тубыли китаплары, галимә Фирдәвес Гарипованың Сарабиккол су чыганаклары турындагы материалы, Казан Дәүләт Университетының танылган галиме Әхмәтҗан Шәмсетдиновның Тубыли турындагы хезмәте, шулай ук КДУ галиме Әнвәр Шәриповның «Габдерәхим Утыз Имәни әл Болгари» дигән күләмле китабы һәм башка чыганаклар Сарабиккол авылы турында шактый гына мәгълүматлар бирә.

Авыл тирәсендә табылган керамик кыйпылчыклар авылның Болгар чорында формалаша башлавы турында сөйли («Археологическая», 1989, 7–8)

1718–1725 елларда үткәрелгән беренче ревизия вакытында авыл турында мәгълүматлар юк.

1746 елда үткән икенче ревизия документларында Сарабиккол турында берникадәр информация бар. Бу авылда 56 ир-ат булган. Кешеләр балчык өйләрдә, талчыбыктан үрелгән һәм сыланган корылмаларда, землянкаларда яшәгәннәр.

1785 елда авылда 114 ир заты яшәгән.

1795 елда авылда 28 йорт булганлыгы, 91 ир кеше, 87 хатын-кыз яшәве билгеле.

Шуннан соңгы елларда авылда йортлар һәм анда яшәүчеләр саны күпкә арта барган.

Башкортстан фәнни-тикшеренү институты архивы

материаллары Сарабиккол авылының яшәү таңында бу авылга нигез салучы кеше Бикколның 1725 елда, аның туганы Якубның 1720 елда дөньяга килгәнен исәпкә алсак, авыл 1720 елларда оеша башлаган дип фаразларга нигез бар. Авыл өлкәннәре (бигрәк тә авыл тарихы белән кызыксынучы шәхес Сәхип Нурлыгатасының бабасы моннан шактый күп еллар элек үк инде авылның барлыкка килә башлавына 400 еллар чамасы икәнлеге турында сөйли торган булган). Ләкин моны исбат итәрлек документлар юк.

## Авыл каберлекләре турында.

Авылда ике каберлек бар. Берсе Мөгәҗи тавы, икенчесе Әхмәт тавы итәгендә.

Кеше гомеренең йомгак очы тәмамлана торган изге урын-каберлек. Анда Әби авылы тарихы шаһитлары урын алганнар, җирләнгәннәр. Тормыш яшәеш тәҗрибәсе тупланган шәхесләр күп нәрсәләр турында сөйләрләр иде. Әмма, алар турында кыска гына мәгълүматне кабер өстенә куелган ташлар гына сөйлиләр. Һәр шәхес узе бер тарих, онытырга ярамый торган тарих. Шуның өчен дер, бәлки, авыл халкы каберлекләргә игътибарлы. Ел саен каберлекләрне тәртипкә китерү буенча өмәләр үткәреләә. Бу өмәләргә авылның шактый күп кешеләре һәм оешма членнары катнашалар. Җирле үзидарә оештыручы орган буларак катнаша.

Сарабиккол тирә-якта өлкән тарихлы авыл буларак, фәнни хезмәткәрләрне дә үзенә тарта.

1964 елларда авылга Альфред Халиков килде. Ул авыл каберлекләрен өйрәнде. Аңа мәктәп укучыла-

ры да булыштылар. Эш болай башланды: башта ул үзе белән таныштырды (Казан дәүләт университеты фәнни хезмәткәре).

Укучыларга эшнең максатын аңлатты, төрле авыллар-да төшерелгән кабер ташлары рәсемнәрен күрсәтте. Шун-дый ташларны тәртип белән эзләргә кушты. Нәтиҗәдә Мөгәҗи каберлегендә (урта бер өлешендә) 15XX елгы таш табылды. Аны табучы Сафин Абугали улы Гамил. Ул хәзер ташның баштагы ике цифрын яхшы хәтерли, соңгы ике цифрын ачык хәтерләми (1581, 1590, 1595 һ.б. булуы мөмкин).

А. Халиков авылның бу елларда оеша башлавын әйткән.

2013 елның 20-22 апрелендә кабер ташларын өйрәнү буенча ике төркем төзелеп тикшерү үткәрелде, өйрәнү үткәрелде.

Мөгаҗи каберлегендә эшләделәр:
Шиһапов Фәрит Хәсән улы
Сафин Абугали Нургали улы
Әхмәт тавы каберлегендә эшләделәр:
Юсупов Җәмил Әхмәт улы
Яһүдин Рәис Корбангали улы
Төхвәтуллин Әнәс Алтынбай улы
Якупов Рәшит Кыяметдин улы.
Төркемнәр өлкән ташларны сайлап өйрәнделәр.

## Күзәтү нәтиҗәләре:

| Куак очы каберлеге | Кирлегәч ягы каберлеге |
|---|---|
| Ташларны урнаштыру еллары | |
| Еллар гарәпчә-хәзергечә | Еллар гарәпчә-хәзергечә |
| 1656 | 1897 |
| 1651 | 1891 |
| 1625 | 1894 |
| 1897 | 1891 |
| 10XX | 1894 |
| | 1595 |

Авыл каберлекләрендә тикшерүләр үткәрү Әби авылының кайсы чорда барлыкка килүе турындагы фактларга өстәмә булып тора.

Кабер ташлары нык җимерелгән, ашалган. Гади таш кисәкләре күп. Ташларда тамгалар очрый (саннарны гарәпчәдән безнеңчәгә күчереп бирделәр Сарыймова Фатыйма, Сарыймов Ренат – Ислам университеты студенты).

Бер кабер ташына (Куак очы каберлеге) кыскача чагыштырма анализ ясарга тырышып карыйк.

Кабер ташындагы 1656 саны бу кешенең 1656 елда вафат булуын ачыклый. Үлгәндә аңа 56 яшь булган. Туган елы 1600 нче ел. Әтисе 20 яшьтә гаилә корган дип фаразлыйк. Шул исәптән аның 1580 елда дөньяга килүен раслый. Бу саннар Сарабикколның (ул вакытта исеме булмаска да мөмкин), беренче ревизиягә кадәр (1718 – 1725) булуын ачыклый. Халык телендә каберлекләрнең Кирлегәч

ягындагасы өлкән дигән сүз йөри. Бу каберлекнең көньяк өлеше борынгыга охшый. Ташларның күпчелегендә язулар юк, саннар да юк, ә тамгалар ешь очырый. Мисал өчен кояш балкышы фигурасы

Уклар төрле юнәлештә ←, ↑, →, ↓, һ.б. Тамгалы ташларның күп булуы каберлекнең өлкән булуын сөйли.

Табылган ташларның тамгалары:

 Кояш балкышы

Төрле юнәлештәге уклар ↑ ↓ ⇆

Геометрик фигуралар > ∧ ∨ ⊡

Булачак авыл җирлегенә кешеләр көнбатыштан – хәзерге Яр Чаллы, Чистай, Казан арты районнарыннан килгәннәр. Көнчыгышка хәрәкәт Шушма, Кичү елгалары арасындагы тигезлекләр буйлап барган. Күченү процессы шактый авыр шартларда уза. Күчеп килүче халыкларны типтәр-бабуллар дип атаганнар (җирсез авыл халкы).

1710–1740 еллар – күченү чоры. Электән сакланып калган риваятьләргә күз салсак, көнбатыштан килүчеләр төркем-төркем булып күченгәннәр. Алар арасында бәлки Сара белән Биккол да булгандыр? Икенче бер риваятьтә исә кешеләрнең көнчыгыштан көнбатышка таба агылуы турында да әйтелә. Шулар арасында бер хатын-кыз да булган. Бәлки нәкъ менә ул гүзәл Сарадыр? Ул «Каенлы чишмә» тирәсендә тукталган. Аның артыннан килүчеләр дә булган. Килүчеләр башкорт ягыннан булган булса кирәк. Аларның исемнәре шуны раслый: Биккол, Толбай, Тимербай, Алтынбай, Карабай һәм башкалар. Хәзер бу чишмәне «Изгеләр чишмәсе» дип йөртәләр.

1740 елларда халыклар төп ике юнәлештә көчәнгәннәр: көнбатыштан көнчыгышка һәм капма-каршы юнәлештә.

Көчәнү сәбәпләре төрле:

1. 1678 елдан башлап, морҗа башыннан ясак түләү кертелгән. Аны түләү халык өчен авыр булса да, әллә ни каршылыклар тумый.

1718 елда, патша казнасын тагын да баету максатыннан, җан башына салым кертелә (инде гаиләдәге һәрбер кеше исәбенә салым түләнергә тиеш була). Шул җәһәттән, 1718 елда беренче ревизия үткәрелә.

Халык белән байлар, алпавытлар һәм патша арасында каршылыклар туа. Бу көрәштә татарлар белән бергә башкортлар һәм башка милләт халыклары да катнаша. Авылларның иң яхшы җирләре байлар карамагында булган. Салым түли алмаган крестьяннарның җирләрен дә алпа-

**Ин борынгы каберлек. Сара белән Биккол шунда күмелгән дип фаразлана.**



вытлар, байлар тартып алган. Халык арасында ризасызлык көчәя һәм шуның аркасында авылларда крестьяннар баш күтәрә, байларның утарларын яндырып, яхшырак җирләр эзләп, качып китәләр.

2. 1713–1740 елларда рус булмаган халыкларны көчләп чукындырулар башлана. Үз ирекләре белән чукынган татарларны өч елга салым түләүләреннән азат иткәннәр. Алар өчен салымнарны чукынырга теләмәгән татарлардан түләткәннәр.

1742–1748 елларда көчләп чукындыруга каршы көрәш тагын да көчәя. Чөнки патша чыгарган Указ нигезендә мәчетләр сүтелә. Бу хәл мөселманнар өчен аерата авыр була.

Күченеп килүчеләр төрле җайлы, аулак, тыныч төбәкләргә урнашып калганнар. Булачак Сарабиккол авылы урыны бөтен яклап та нәкъ шундый – җайлы урын булган.

3. Сарабиккол авылының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш якларындагы бик уңдырышлы басулар 1738 елдан башлап, Иске Куак җирләренә кушыла. Бу якларга Польшадан, мәҗбүри тәртип саклау өчен дип, поляк солдатлары китерелә. Поляк шляхтичлары салым түләмәгән. Патша шундый юл белән яңа җирләр үзләштерүне җайга салган.

Соңрак шушы ук урынга ике балалы тол хатын Сара килеп урнаша. Балаларының язмышы безгә билгеле түгел. Халык арасында сакланып калган сүзләргә игътибар итсәк, улларының берсе Самара өлкәсендәге Шанталы районының Карабиккол авылына нигез салган. Икенче улын хатын үзе белән алып килгән. Шулай, Сарабиккол авылына (Әби авылына) Сара үзе нигез салган дип фараз кылыйк.

Сара белән Биккол шунда гаилә корып яши башлыйлар. 1751 елда Сараның Сәлим исемле улы дөньяга аваз сала. Самара һәм Уфа дәүләт архивлары материалларыннан күренгәнчә, ул баланың фамилиясен Сарабиккулов дип атап йөртә башлаганнар (Сарабикколов Сәлим, Биккулов Сәлим исемнәре архив документларында еш очрый). Шулай булгач, Биккол Сараның ире була түгелме соң?

## Халык риваятьләреннән

Борынгылар сөйләве буенча, бу төбәккә беренче булып, Әхмәт исемле гаиләле бер кеше күченеп килә. Көнбатыштагы тау итәгенә йорт салырга ниятли. Тик эш башы белән ул уңышсызлыкка дучар була – арбасы ватыла. Уңышсыз башланган эш хәерле булмас дип, ул бу тау итәгеннән икенче якка күчеп китә. Халык телендә бу тау Әхмәт тавы дип аталып йөртелә башлый.

Әхмәт тавы турындагы риваятьнең халык телендә тагын бер төрлесе дә яшәп килә: Әхмәт атка атланып юлга чыккан. Әмма аты дулап китә дә ул елгага егылып төшә һәм шунда вафат була. Ул егылган елганы Әхмәт елгасы дип йөртә башлыйлар.

Авыл турында тагын бер риваять: бу төбәккә чак кына соңрак Сара исемле бер тол хатын килә. Ул үзе Самара ягыннан була. Ире һәм кызы үлгәч, безнең якларга юл тоткан икән ул. Сара үзе белән ике улын да ияртеп килә. Имеш, бер улы Самара өлкәсендәге Карабиккол авылына нигез салган, шул җирдә тормыш кабынып китүгә башлангыч биргән. Икенче улының язмышы билгеле түгел. Сараның үзенә Шушма буе болынлыклары, кара туфраклы җир кишәрлекләре ошый. Ул бу төбәктә тукталып кала, шунда яши башлый.

Бу төбәккә халыклар төрле яклардан күченеп килгәннәр: көнчыгыштан – башкорт кабиләләре, көнбатыштан типтәр-бабуллар, төньяктан чуваш, мордва, удмуртлар күченгән. Күченгән халыкларның күпчелеген типтәр-бабуллар тәшкил иткән. Качып күчеп килүче типтәрләр күп булган. Алар үзләре белән мөселман динен алып килгәннәр. Күчеп килгән башка халыклар да мөселман динен кабул иткәннәр һәм балаларына да татар исемнәрен кушканнар.

Башкорт кабиләләре белән дә шундый ук хәл күзәтелгән. Алар типтәрләр белән күпкә җиңелрәк, ансатрак аралашканнар.

Бу төбәккә яраклашып калучылар арасында авылга башлангыч биргән шәхесләр дә булган: Мирзагол, Бикқол, Фәйрүз Карабаев, Сәлим Бикколов һәм башкалар.

Бик борынгы заманнарда халыклар кабилә булып оешып яшәгәннәр, күчмә тормыш алып барганнар. Сарабиккол авылына нигез салучы (Мирзагол, Биккол, Якуб–Карабай) нәселләре «Мин» кабиләсенең бер өлешен тәшкил иткәннәр. «Мин» кабиләсе 11 волстне берләштереп бик зур мәйданны биләгән, Караидел (Кама), Минзәлә, Ык елгалары үзәннәренә кадәр килеп урнашканнар. Һәр волостнең үз исеме һәм аерымлык билгеләре булган. Мәсәлән: Кулили-минская, Сарали-минская h.б.

Мин кабиләсенең агачы – каен, уңыш китерүче кош – карчыга, Уран (чакыру), Алас (ут).

Тамгалары: 

Бу башкорт кабиләләре көнбатышка (безгә) Бәләбәй тау итәкләреннән күченеп килгәннәр. Мал асрау, балык тоту, соңрак игенчелек белән шөгыльләнә башлаганнар. (Уфа дәүләт фәнни үзәге, тарих институты мәгълүматлары буенча).

эшләре башланды. Соңрак бу эшкә Керкәле авылы кешесе Шамил Сафин җитәкчелек итте. Күпер тирә-як авыллары халкына 25 ел хезмәт итте.

1997 елда Шушма елгасы аша капиталь күпер салу эшенә керештеләр. Чаллының «Мостстрой» оешмасы бу эшне үз өстенә алды. Яңа күпер 2000 елның 26 августында ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин, район хакимият башлыгы И.Ә.Садриев, «Урал» колхозы рәисе Әсхәт Төхвәтшин катнаштылар.

## Мәчетләр авыл тарихын сөйли

Авылыбызның күрке – изге мәчет.
Ул тора илебез сагында.
Күңелләр куана,халыклар
Намазга барган чагында.

***Резеда Абдуллина.***

Сарабиккол – бу төбәктә иң зур һәм төзек, мәгърифәтле авылларның берсе. Оешканнан алып, яшәү дәверендә авыл зур үзгәрешләр кичергән. Яшәеше уртасында анда 450дән артык йорт исәпләнгән (2007 елда 296 хуҗалык исәпкә алынган). Күренекле антрополог, сәяхәтче, табигать белеме галиме П.С.Паллас Урта Идел халыкларының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен өйрәнгән чорда (18 нче гасырда) безнең авыл аша узган. Аның мондый язмасы сакланган: «Биккулово таулар арасына сыенып утырган авыл, тулы сулы елгасы һәм бер су тегермәне бар». Игътибарлы галим авылда мәчет күрмәгән, димәк, бу елларда безнең авылның аерым мәчете булмаган әле. Картлар ул чорда җомга намазларын өйләрдә җыелышып укыган булсалар кирәк.

лар да бар. Бу – бер фикер. Икенчесе – Куак очында ут чыгып, зур янгынга (1905 елда) бәйләп аңлатыла. Ләкин бу фараз дәлилләнмәгән.

Соңга таба шул күпердән 200–300 метр гына түбәнрәк җирдә яңа күпер сала башлаганнар, аңа тоташкан юл биегрәк җирдән, ягъни тау буеннан узган. Бу күпер 1929–1930 елларда, шулай ук имән агачыннан салына. Ул да халыкка озак вакытлар буе хезмәт итә.

1946 елларда көчле ташу төшеп, күперләр җимерелде, нәтиҗәдә аргы як белән бәйләнеш тә өзелде. Кешеләр Шушманың икенче ярына бары тик көймәләрдә генә чыга ала иде, бу бик үк уңайлы түгел, билгеле. Шуңа да аргы якка бары тик кичектергесез мотлак эш башкарырга кирәк чакта гына чыгалар. Мәсәлән, чәчүлек орлыкны шулай көймәдә ташыдылар.

Су кайткач, Камил Корбанов (Рәшит, Фоатлар) урамы башына вакытлыча чыбык күпер салдылар. Күпер өстенә чыбык түшәп, аны тирес белән капладылар. Күпер авылның ике өлешен тоташтырып, бәйләп торды. Агып киткән күпер урынына шул ук елны кыш көне (1946–1947 ел кышы) агач күпер төзелә башлады. Аның өчен тирә-як авыллардан төзүчеләр китерелде, чөнки күпер юклык бу авыллар тормышына да зур кыенлык тудыра иде. Баганалар утырту (субай кагу) авыр гер белән кулдан башкарылды. Төзелештә авыл Советы рәисе Фәхразый Авширов актив оештыручыларның берсе булды.

Күпер салуда даими эшләүчеләрдән Исмәгыйль Мусин, Хөсәен Әскаров, Хәсән Мифтахов, Рәшит Корбанов һәм башкаларны санап үтәргә мөмкин. Күпер төзү материалларын Хәтиф Мостафин саклады.

1961–1965 елларда район юл төзелеше бүлеге прорабы Хәеров җитәкчелегендә ныклы (цемент) күпер салу



18 нче гасыр ахырында авылда 4 мәчет эшләгән. Авыл халкы дүрт мәхәлләгә бүленгән. Бу мәчетләр аларны төзүчеләрнең һәм анда эшләгән дин әһелләренең исемнәре белән атап йөртелгәннәр.

**Фәхретдин мулла мәчете.** Мәдрәсәле мәчет урта урам башында урнашкан. Бу мәчетне Фәхретдин мулла үзе салдырткан, шуңа ул аның исемен йөртә. Мулла гарәпчә яхшы укый-яза белгән, рус телендә дә җиңел аралашкан.

**Ямалетдин хәзрәт мәчете.** Аны авыл хисабына салганнар. Хәзрәт үзе читтән килеп эшләгән. Мәчеттән көньякка таба 100 метрлап арырак 8 почмаклы мәдрәсә бинасында ир балалар укыган. Бу мәчеттә Ямалетдиннан соң Шакирҗан хәзрәт мулла булган.

**Шакир мулла мәчете.** Бусы хәзерге мәдәният йортыннан өстәрәк иде. Бу мәчет тә халыктан җыелган акча хисабына төзелгән булган.

**Әкрам мулла мәчете.** Хәзерге Рәсим Бәдгытдинов

йорты белән «Алан» кибете тирәсендә урнашкан мәчетне төзүдә авыл байлары үзләреннән зур өлеш керткән.

Мәчетләр барысы да агачтан бурап салынган, калай белән ябылган.

...Революция чорлары үтеп, колхозлашу вакыты җитә, сугыш еллары якынлашып килә. Дәүләт мәчет һәм чиркәүләрне бетерү, динне дәүләттән аеру сәясәтен алып бара.

Сарабиккол мәчетләренә дә чират җитте. Авылдагы манаралы бердәнбер мәчетнең (Ямалетдин мәчетенең) манарасын кисеп аудардылар. Бүрәнәләрен сүтеп, ике катлы мәктәп бинасы янына ташыдылар, тагын бер мәктәп бинасы корып куелды. Бу мәктәпнең түбәсен генә ябасы калган иде инде.

Ләкин Бөек Ватан сугышы башланды, мәктәп түбәсе ябылмыйча калды, бурасы череп таралып, ишелеп төште. Шакир мулла мәчетен башта балалар бакчасы иттеләр, аннары колхозның орлык склады итеп ясадылар, соңрак исә клуб итеп үзгәртеп кордылар.

Тулы булмаган мәгълүматларга караганда, иске клубның тузуы, яңа клуб кирәклеге турында Мостафа Моратов ул чакта КПСС Үзәк Комитетының генераль секретаре Л.И.Брежневка хат яза, яңа клуб салуда ярдәм итүләрен сорый.

Шуннан соң клуб төзелеше башлана. Ул төзелеп беткәч, мәчетне сүтеп, бүрәнәләрен урмандагы умарталыкка ташыйлар. Склад һәм умарталар йорты салу планы туа, ләкин ул ният тормышка ашмый, бүрәнәләр шунда урманда череп бетә.

Башка мәчетләр дә шундый ук язмышка дучар ителде. Мәчетләр бетте.

Авыр сугыштан соңгы михнәтле елларда мәчет са-

лу өчен халыкның да, авыл Советының да, колхозның да көче юк иде. Авыл картлары җомга намазларын авылның буш йортларында укып йөрделәр. Шундый җомгаларның берсендә авыл өлкәннәре (Хәниф Хәкимов һ.б.) авылга мәчет кирәклеге һәм аны таштан салу зарурлыгы мәсьәләсен күтәрделәр. Әлбәттә, бу эшне колхоз идарәсеннән, авыл Советыннан башка эшләп булмый. Шуңа да башта алар белән киңәшергә кирәк иде. «Урал» колхозы рәисе Мөслим Хәбибуллин, авыл Советы рәисе Фәрит Шиһапов өлкәннәргә, барлык булган мөмкинлекләрдән чыгып, ярдәм итәргә сүз бирделәр һәм алар сүзләрендә тордылар.

Төзелеш мәчет өчен урын сайлаудан башланды. Мәчет авылның уртасында булырга тиеш. Элеккеге янгын сарае тирәсе кулай булыр дип табылды. Мәчет юнәлеше белән кыйблага, ягъни Мәккә ягына карап торырга тиеш. Юнәлешне дөрес билгеләү өчен география укытучысы Рәшит Якуповка мөрәҗәгать итәләр. Географик координатлар ярдәмендә тиешле юнәлеш билгеләнде һәм эш башланды.

Мәчетнең нигезен салуда (казу, цементлау эшләрендә) бик күп кешеләр катнашты. «Татбитум» оешмасының Риф Вәлиев җитәкчелегендәге Кармалка участогы нигез салу эшләрен бик тиз, төгәл һәм оста башкарып чыкты. Бу төркемдә төп эшче көчләр Миңнебай Гарифуллин, Хәмбил Мортазин һ.б. булдылар.

Мәчетне төзүдә авыл халкының матди ярдәме зур булды. Һәр гаилә көченнән килгән кадәр ярдәм кулы суздылар. Авыл өлкәннәре бу күренешне «яхшы» дип бәяләделәр. Авылда дин учагы сүнмәскә тиешлеген даими аңлатып тордылар.

Мәчет стенасын өюдә авыл осталары эшләде. Менә

алар: Хөсәен Ялаков, Исмәгыйль Мусин, Әсхәт Локманов, Хәлил Локманов, Рубин Мусин, Искәндәр Сәхипов.

Агач эшләрен башкаручы балта осталары (идән җәю, ишек-тәрәзәләр кую, кыекны эшләү һ.б.): Рубин Мусин, Исмәгыйль Мусин, Хөсәен Әскәров, Закир Гыйлалов, Әнвәр Газимҗанов. Материалларны табып китерү, кайтару эшләре өмә итеп башкарылды.

Мәчетнең проектын колхоз рәисе М.Хәбибуллин проект бүлегендә эшләтеп кайта, ә манара сызымын Р.Мусин кулдан эшли. Мәчетне теркәү документлары артыннан Р.Мусин йөрде, аннары М.Хәбибуллин Уфа шәһәренә барып, рөхсәт кәгазьләрен эшләтте. Мәчет манарасын эшләтүдә түбәндәге шәхесләр актив катнашты: Рәфкать Алтынбаев, Фәнил Ялаков, Закир Гыйлалов, Исмәгыйль Мусин, Рубин Мусин. Мәчет төзелешенә кирпеч табу мәсьәләсен Алтынбаев Рәфкать хәл итте, ә акчасын Әкъдәс Мортазин түләде.

Электр линиясен сузу, эчкә ут үткәрү эшен Наил Садыйков, Фәнис Гыйлалов, Рөстәм Шиһаповлар башкарды. Эчке җылылык системасын үткәрү Мөдәррис Латыйпов һәм аның кул астында эшләүче газчылар тарафыннан башкарылды. Мәчетнең манарасын күтәрү һәм урнаштыруда газ һәм электр ярдәмендә эретеп ябыштыручы Мөнир Баһауов зур тырышлык салды.

Шулай итеп, элеккеге агач мәчетләрдән аермалы буларак, бу юлы таш мәчет төзелде. Мәчет хәзер авылга ямь биреп тора. 1998 елның сентябрь аенда биредә беренче җомга намазы укылды. Хәзер мәчеткә өлкәннәр белән бергә яшьләр дә йөри. Авыл халкы көн дә азан тавышын ишетеп яши. Гомерле булсын ул азан моңнары!

Хәзер мәчет бу төзелештә бик зур ярдәм күрсәткән кеше – Фәнил Ялаков исемен йөртә. Сүз уңаеннан, тө-

зү материаллары белән ярдәм итүчеләр: эшмәкәр Равил Фәйрүзов, Әкъдәс Мортазин. Мәчетне төзүдә бик актив катнашкан кешеләр: И.М.Мусин, З.Гыйлалов, Х.Әскаров, Ә.Газыймҗанов, Р.Мусин. Бу игелекле кешеләргә барлык авыл халкы исеменнән зур рәхмәтләрне ирештерәбез!

Соңгы елларда авылда имам-хатыйб вазыйфасын Әнвәр улы Альберт хәзрәт Насрыев алып бара. Ул мәчет янәшәсендә мәдрәсә салдыру планы белән яши. Бу ният тә тормышка ашса, бик күркәм булыр, иншалла.

Альберт хәзрәт Насрыев тырышлыгы һәм «Сатурн» җәмгыяте генераль директоры Равил Сәгыйть улы Фәйрүзовның матди ярдәме белән 2007 елның август аенда мәдрәсә төзү эшләре башланды. Нигезен Фоат Усманов, Фәрит Шиһапов, Илдар һәм Илдус Фәрхетдиновлар салды.

## Мәчет-мәдрәсәләр һәм танылган дин әһелләре

1890 елда авыл мәчетендә 33 яшьлек Җамалетдин Мөхәммәтшакир улы Низаметдинов имам һәм мөгаллим булган. Авылда бер мәдрәсә. Җамалетдин мәдрәсәдә ир балалар укыткан. 1890 елның сентябрендә имам булып расланган. 1889 елда төзелгән мәчеттә 42 яшьлек Җамалетдин Ногманов имам хатыйб була, ул 1890 елның мартында раслана. Х ревизия мәгълүматларына караганда, мәчеткә 251 ир-ат даими йөргән.

1890 елның 26 мартында 42 яшьлек Мирхәйдәр Низаметдинов икенче мулла булып раслана.

1894–1895 елларда авылда указлы мулла булып Шаһвәли Явишев торган (л. Л. 36 об – 37).

Сарабиккол авылы тирә - якта зур авылларның бер-

Биредә 4 мәчет эшләп килгән, 3 мәдрәсәдә балалар укыганнар. Мәчеткә йөреп дин тотучыларның саны X нчы ревизия буенча 1895 нче елда 300 ир – атка җиткән. Җомга намазларын һәр ир – ат үз мәхәлләсендә укыган. Авылның күпчелек халкы мәдрәсәләргә йөреп укырга, язарга өйрәнгәннәр.

Авылда грамоталы шәхесләр, дин әһелләре шактый күп булган. Авыл тарихына кереп калган берничәсе турында язманы дәвам итик. Муллалар – авыл халкын мәгърифәткә өндәүчеләр. Алар арасында да мәчет тирәсендә бер – берсе белән килешмәүчәнлек яшәп килгән. Авылның беренче җәмигъ мәчетенең указлы мулласы Шаһвәли Габделваһап улы Явишев турында. Ул 1894 – 1895 елларда авылда указлы мулла хезмәтен башкарган. Бик укымышлы шәхес. Аңа көнләшеп карачылар авыл типтәрләре Зариф Солтанов, Мостафа Мозафаровлар була. Алар Шаһвәлинең даими эчүчелеккә, җенси бозыклыкка бирелүе турында шикаят язалар. Шаһвәли бу шикаятне гаделсезлек дип саный. 1885 нче елның 4 апрелендә Самара волысте Шаһвәли эше буенча тикшерүләр үткәрә. Шул тикшерүләр нәтиҗәсендә 25 кешенең дәлилләре Шаһвәли файдасына була. Пристав сорау алу беркетмәләрен югары органнарга җибәрә (нигезләмә: ЦГМАРБ ФИ295 ОП – 8Д 1054).

Сарабиккол авылы тарихына кагылышлы материалларны эзләү дәвам итә. 2011 нче елда авыл тарихына ачыклык кертүче кульязма китап табылды. Ул Кашаповлар гаиләсендә, аннан соң Нажия Баһаутдинова гаиләсендә саклаган. Кульязма китап 650 биттән тора, гарәпчә язылган. Язмалардагы соңгы дата – 1851 нче ел. Язылу урыны – Сарабиккол авылы. Кульязманың авторы – Сарабиккол авылының имамы Шаһвәли Габделваһап улы Яви-

шев. Китапта шәригать кануннары, халыкның көнкүреш тормышы һәм кайбер башка өлкәләр яктыртылган.

Китапны укыгач, ул чор кешеләренең тормыш рәвеше күз алдына килеп баса. Мәсәлән, кульязмадагы мәгълүматка таянсак, Сарабиккол авылында ул чакта 4 кибет булган. Акчасы булмаган кешеләргә бурычка да биреп торганнар, һәр кибетчедә әҗәт дәфтәре булган. Бурычка алучы шул китапка әҗәтенең күләмен күрсәтеп, билге куйган. Бурыч шактый күләмдә булса, авыл мулласы имзасы белән расланган (3 кеше тамга куйган: сатучы, алучы һәм мулла). Кайбер очракта бурычка алучы, акчасы булмау сәбәпле, әҗәтен арышлата түләгән. Ул чор кешеләре арыш культурасын күп игә торган булганнар, күрәмсең. Кульязмада бодай культурасы телгә алынмый. Анда бәяләр турында мондый мәгълүмат бар:

Бер подаука (16 кг) арыш – 73 тиен.

Бер сарык – 3 сум 10 тиен.

Бер чирек чәй – 1 сум 62 тиен.

Бер кадак (400 гр) бал – 3 – 4 сум.

Тоз Оренбург өлкәсеннән кайтарылган. 1 потын (16 кг) 35 тиенгә сатып ала торган булганнар.

Шаһвәли Габделваһап улы Явишев язган китаплар:

Хакимиятне тану, аңа буйсыну.

Шәригать сыйфатларының мәгънәләре.

Хакимияттә шәфәгать һәм кайгыртучанлык.

Сөекле булу турында.

Әҗәл турында.

Әманәт.

Фикер алышу, уртага салып сөйләшү.

Чиркану һәм җирәнү, көчләнеп яшәү.

Тырышлык.

Изгелек кылу һ.б.

Авылда элекке заманнарда да мәгърифәтле кешеләр шактый күп булган. Шундыйларның берсе Шаһвәли Габделваһап улы Явишев.

Ул "Китап җәмигъ" хезмәтен бик зур төгәллек белән нәфис итеп кулдан язган (кульязма китап). Китап язу өчен каләмне су буенда үсә торган каты камыштан ясаган, кара итеп карт имән каерысын кайнаткан (чернила). Бу кара белән язылган язмалар яхшы сакланганнар. Байлар кытайда эшләнгән караларны файдаланганнар, ул кызыл һәм кара төстә булган, озак сакланган.

Вакыт елгасы аккан да аккан. Үзе белән бик күп тарихый мәгълүматлар алып килгән. Бу мәгълүматларны берләштерү, тәртипкә салуда камыш каләм белән бер рәттән каурый каләмнәр дә өстенлек ала барган.

Сарабиккол авылында туган һәм яшәгән Әхмәтҗан Тубыли Эл Болгариның күпчелек шигырьләре каурый каләм белән язылган дип фаразлыйк. 20 нче гасыр елларында кеше металл каләмгә күчкән, аны шариклы һәм автокаләм алыштырган. Хәзерге көндә санап киткән каләмнәрне компьютер дигән могҗиза алыштыра бара.

**Фәхретдин мулла.**

Фәхретдин Хөснетдинов 1874 елда Сарабиккол авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Казанда укып, белем ала, соңыннан Уфа шәһәренә китеп, анда мөгаллимлек итә. Берникадәр вакыттан соң ул туган авылы Сарабикколга кайтып, үз акчасына мәдрәсә салдыра һәм шунда балаларга дин дәресләре укыта. Әлеге мәдрәсәгә, белем алырга дип, тирә-як авыллардан да балалар килә. Берничә елдан соң авылда яңа мәчет салына, бу эштә дә Фәхретдин мулла иң күп тырышлык куючы була. Мәдрәсә-мәчетнең урыны хәзерге урта урам белән юл (шоссе)

арасында Зәйтүнәләр йортыннан әз генә көнбатышка таба булган.

1930 елда Фәхретдин мулланы Себергә озаталар, әмма 1937 елда аны гаепсез дип табалар һәм ул реабилитацияләнә. Бөек Ватан сугышы елларында Фәхретдин мулла оборона эшләрендә катнаша, 1944 елда Мәскәүдә вафат була.

**Ямалетдин хәзрәт.**

Ямалетдин хәзрәт мәчеттә эшләргә чит җирдән килгән булган. Мәчет авыл халкы акчасына салынган, урнашкан урыны – Куак очы зиратыннан астарак, элекке балалар йорты, хәзер төзелеп бетмәгән балалар бакчасы урынында.

Мәчеттән 140–150 метрлап аста ике бүлмәле мәдрәсәдә бары тик ир балалар гына укыган.

Ямалетдин хәзрәт сәнәкчеләргә (1919–1920 елларда) теләктәшлек күрсәтә, шуңа күрә аны кулга алалар, соңрак атып үтерәләр.

**Шакирҗан мулла.**

Кызганычка, Шакирҗан мулла турында мәгълүматлар бик аз. Бары тик аның да читтән килгәнлеге, Ямалетдин хәзрәттән соң муллалык итүе генә билгеле.

**Шакир мулла.**

Хәзерге мәдәният йорты янында, Наил Шәяхмәтов йорты яныннан аз гына астарак, яңа мәчет төзелә. Анда берничә ел рәттән Шакир мулла хезмәт итә. Аның үз йорты хәзерге Әсхәт Сарыймов йорты урынында булган.

**Әкрәм мулла.**

Әкрәм мулла эшләгән мәчет Талыйп Бәдгытдинов йорты каршында, хәзерге «Алан» кибете урынында булган. Әкрәм мулла турында шулай ук башка фактлар билгесез.

**Талыйп хәлфә.**

Аның яшәгән йорты Хәтиф Мостафинның сарае урынында булган. Талыйп хәлфә бары тик кыз балаларга гына дин сабаклары биргән, аның мәдрәсәсендә нибары 15 кыз бала гына белем алган, чөнки авыл халкының күпчелеге, укый-яза белгән кызлар егетләр белән хат алыша башлар дип куркып, кызларын укытмау ягында торган.

Талыйп хәлфә гомеренең соңгы елларын Шанталы станциясендә уздырган.



**Габдерәхим Утыз Имәни әл Болгари.**

Бу танылган шәхеснең дә безнең авылыбызга мөнәсәбәте бар. Утыз Имәни – бөек язучы, күп кенә әсәрләрен бүгенге филологлар да өйрәнә.

Урта Азиядәге Сәмәрканд, Бохара шәһәрләрендә, Әфганстандагы Кабул шәһәрендә һәм башка җирләрдә белем алгач, ул туган ягы Утыз Имәнгә кайта, әмма аны кабул итмиләр, шуңа ул башка авылларга китәргә мәҗбүр булла.

1801–1804 елларда ул Сарабиккол авылының бер мәдрәсәсендә хәлфәлек итә. Аннан соң Куакбаш авылына күчеп, үз акчасына анда мәдрәсә салдыра, озак вакытлар

шунда эшли. Гомеренең соңгы елларын Тимәш авылында үткәрә һәм 80 яшендә шунда вафат була.

**Утыз Имәни нәселе**

Беренче курста безне татар әдәбиятыннан Навар Әхтәмова дигән укытучы укытты. Үзенең бер дәресендә ул Габдерәхим Утыз Имәни әл Болгари турында сөйләде. Аның Сарабиккол авылында хәлфәлек итүе турында да әйтеп узды.

Күп еллар узса да, укытучымның бу сүзләре минем хәтеремә сеңеп калган. Миндә Утыз Имәни турында күбрәк белү теләге туды. Авыл өлкәннәреннән сораштыргаладым – белүче юк. Яшь буын кешеләре арасында да сораштырулар булды.

Яшьләр хәтерле. Габдерәхим турында беренче мәгълүматны Мөслимә Мөхәммәтгалим кызы Сафина ачты. Аннан соң аның энесе Өлфәт Мөхәммәтҗанов шактый өстәмәләр бирде. Ул Утыз Имәни турында күп мәгълүматлар җыеп, диссертация яклаган филология фәннәре докторы Әнвәр Шәрипов белән элемтәдә тора (Чаллы дәүләт педагогия институтында укыта).

Инде хәзер төп хикәягә күчик. Габдерәхим (1754–1834) хәзерге Чирмешән районы Яңа Кади авылында дөньяга килгән. 3–4 яшендә ятим калган. Аны бер җиңгәсе тәрбияләп үстерә. Мәдрәсәләрдә белем ала. Укырга омтылышы зур була. Алдынгы карашлы шәхес Габдерәхим күп шигырьләр, поэмалар иҗат иткән, халыкны гыйлем алырга чакырган, матур, имин тормыш төзергә өндәгән. Шигырьләрендә фикер иреген таләп итә. Мәдрәсәләрдә тормыш өчен кирәкле дөньяви гыйлем бирергә чакыра.

Үсеп җитеп, дөнья таный башлагач, Утыз Имәни

авылы кызы Фәтхиягә, ул үлгәч, Хәмидәгә өйләнә. Хәмидә дөньяга ике кыз, бер ир бала китерә. Белемгә омтылышы көчле булу Габдерәхимне Урта Азия илләренә, шәһәрләренә илтеп чыгара.

Күп илләрдә, шәһәрләрдә белем алганнан соң, туган иленә – Утыз Имәнгә кайта. Ләкин аны авылда кабул итмиләр. Аңа әтисенең авылы Тимәшкә кайтырга кушалар. Шуннан соң ул берничә авылдагы мәдрәсәләрдә хәлфәлек итә.

1801–1804 елларда Сарабиккол авылында хәлфә була. Шул елларда бер кызын – Хәбипкамалны Сарабиккол кешесе Әхмәтҗанга кияүгә бирә. Әхмәтҗан укымышлы кеше, шигырьләр, поэмалар язу белән дә шөгыльләнгән. Аның төп һөнәре кешеләрдән терлек ите һәм тире җыю була. Үзе җыйган товарны Чирмешән базарына илтеп сата.

Бервакыт товар төяп, Чирмешәнгә барырга чыга бу. Аны Сарабиккол күпере янында туктаталар һәм кеше үтерүдә гаеплиләр (күпер астында үтерелгән ике мукшы гәүдәсе табыла). Әхмәтҗанның кесәсеннән канга буялган пычак табып алалар. (Пычакны канга буяп, сиздермичә генә кесәсенә салучы бәндә аның зур дошманы була). Аны 1871 елда 15 елга Тобольск төрмәсенә ябалар. Иң мәгърифәтле елларын Әхмәтҗан бине Шәмсетдин, бине Сәлим әл Әбәви, әл Болгари, әл Тубыли, шулай итеп, төрмәдә үткәрә.

Әхмәтҗан Тубылиның ике кызы, бер улы була.

Габдерәхим + Фәтхия, Хәмидә, Бәдигылҗамал.

Кызы – Бибиҗамал.

Фазлулла (Куакбаш кешесе, икенче кияве). Әхмәтҗан (улы).

Хәбибкамал. Ире – Әхмәтҗан Тубыли, Сарабиккол кешесе (беренче кияве).

Әхмәтҗан улы – Мөхәммәтҗан. Аның ике кызы, ике улы. Кызлары: Мәхүбкамал (1893–?), Маһитап (билгесез). Уллары: Хафиз (1878 – 1965), Мөхәммәтгалим (1897–1967).

Хафиз (1878–1965) йомшак күңелле, бик укымышлы мулла була. Коръәнне тулы килеш яттан белә.

Балалары: Мөхәммәтшакир (1906–1997). Балалары: Фәрит (1940), Асия (1937), Минзакир (1935–2000), Гаҗилә (1949), Нәзирә (1954).

Габдразак (1912–1943), фронтта һәлак була.

Оркыя (1903–?)

Хәдичә (1905–?)

Кәримә (1920–2000)

Әкълимә (1926), Бөгелмәдә яши.

Мөхәммәтгалим (1897–1967). Балалары: Мәүлет (1923). Балалары: Фоат (1952), Роза (1954), Рәисә (1958), Рәис (1962).

Мәүлет 1942 елдан сугышта катнаша. 1948 елда авылга кайта. «Магнит» колхозында төрле эшләрдә эшли, сельпода склад мөдире, 1953 елдан Бөгелмә балалар интернатында хуҗалык мөдире була.

Мөслимә (1930). Пенсиягә чыкканчы, колхозда төрле эшләрдә эшләде. Балалары: Мөршидә (1951), Ринат (1954), Марат (1958), Флюра (1964).

Өлфәт (1935). 1951 елда Сарабикколда 7 сыйныф тә-

мамлап, Самарада һөнәр училищесына укырга керә. 1953 елда слесарь-сантехник һөнәре алып чыга. Бөгелмәнең 4 нче төзү-монтажлау идарәсендә һөнәре буенча бригадир булып эшли, 1955–1958 елларда Совет Армиясе сафларында Германия Демократик Республикасында хезмәт итә. Армиядән кайткач – шофер. 1964 елда кичке мәктәпне тәмамлап, Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Аны 1969 елда тәмамлап, инженер-механик дипломы ала.

Эшләгән урыннары: Сумаровскида – баш инженер; 1971–1974 елларда Түбән Кама шин заводы төзелешендә катнаша; оешмада баш механик була; Волжск автозаводына эшкә чакырыла; 1974–1983 елларда – Карабашта техник хезмәт күрсәтү станциясе (СТО) директоры. Улы – Рөстәм (1968), Казанда яши һәм эшли.

Мәкъбүлә (1938), Бөгелмә медицина училищесын тәмамлаган, Алабугада яши. Балалары: Әлфия (1961), Зөлфия (1963).

Тәслимә (1942), Лениногорскида югары категорияле табиб-гинеколог, бала тудыру бүлеге мөдире. Улы – Илшат.

Әтиләре Мөхәммәтгалим күп еллар «Магнит» колхозында икмәк складында мөдир булып эшләде. Беренче хатыны Хәлимә вафат булгач, икенче хатынга – Минҗамалга өйләнде. Минҗамал белән уртак балалары булмады.

1950 еллардан соң Сарабикколда мулла хезмәтен башкарган кешеләр шактый күп, без аларның берсе берничәсенең генә исемнәрен китерәбез:

Хафиз мулла, Хафиз Исхаков, Фәхретдин, Ибраһим

Идрисов, Хәтиф Мостафин, Вәлирахман Сәхапов, Камалетдин Мөхәммәтшәрип, Сарыймов Әхтәм һ.б.

Альберт Насрыев.

1998 елда авылның тау башында яңа кирпеч мәчет төзелде. Аны төзүдә бөтен авыл халкы актив катнашты. Хәзергә кадәр әлеге мәчеттә мулла хезмәтен Альберт Насрыев алып барды. Ул Сарабиккол авылында туып-үсә, Казан шәһәрендә югары белем ала, Чаллыда мәдрәсә тәмамлый һәм, туган авылына кайтып, мәчеттә эшли башлый. Альберт Насрыев башка эшкә күчү сәбәпле, хәзерге көндә мулла вазыйфасын Марат Миргасыйм улы Исмәгыйлев алып барды. Ул «Сатурн-Урал» җәмгыятендә агроном эшен дә алып бара иде Хәзер имам булып Камалетдинов Мөхәммәтшәриф эшли. Аның ярдәмчесе Сарыймов Әхтәм Барый улы..

## Төркиягә күченү чоры

Россия тарихында рус булмаган халыкларны руслаштыру сәясәте бик күптәннән (1713–1742 елларда ук) башланган. Идел буе татарлары бу хәлгә һәрвакыт каршылык күрсәтеп килгәннәр. Мәчетләрне сүттерү турындагы Указ (1742 елда) татар халкының патшага һәм аның наместникларына каршы көрәшен тагын да көчәйтә. Патша чиновниклары баш күтәргән һәм каршылык күрсәткән халыкларны җәзалау юлына баса.

1878–1879 елларда татар халкының төп өлеше ярлылыктан һәм җирсезлектән интегә. Ярлылык, җирсезлек, руслаштыру, җанисәп алу – барысы бергә халыкны тәмам куркуга сала. Көчләп чукындырудан, дин бетә дип куркудан, эзәрлекләүләрдән котылу юлын эзләп, кешеләр ка-

раңгы якларга күченә башлый. Шактый күп халык, яхшы тормыш эзләп, Төркиягә сыена, анда яклау табарга өметләнә. Әби авылыннан да Төркиягә күченеп китүче гаиләләр аз булмый: барлыгы 34 гаилә күченеп китә.

Юл газабы – гүр газабы дип, борынгылар юкка гына әйтмәгән... Зур кыенлыкларны җиңеп (алдашулар, талаулар, үтерүләрне үз җилкәләрендә татып), юлларын дәвам итә алар.

Акча запасы булдыру өчен аларга йортларын, каралты-кураларын, терлекләрен юк кына бәягә сатып китәргә туры килә. Сатып алучылар, башлыча, авыл байлары, дин әһелләре була. Төркия хөкүмәтенә зур өметләр баглаган татарлар аннан бер ярдәм дә ала алмыйлар. Күп көннәрдә ачлы-туклы килеш, үзләре белән алган барлы-юклы мөлкәтләрен саклап утырырга мәҗбүр булалар.

Алар Стамбулдан ерак булмаган бер урынга – таулар арасындагы үзәнгә барып урнашалар, үз авылларына нигез салалар. Башта тау куышларында, землянкаларда, чыбыктан үрелгән, балчык белән сыланган өйләрдә яшиләр. Бу урынны алар Кадын-Көй дип атыйлар. Әби авылының Кәлимулла исемле кешесе дә шунда урнашып кала. Аның нәсел очы туганнары Казлы авылында Күпер асты урамында яшиләр.

Төркия Урта диңгез тибындагы субтропик һәм континенталь субтропикларда урнашкан. Биредә яктыртучы кояш та күчеп килүчеләргә рәхимсезрәк карый кебек тоела, кышларын дымлы, явымлы, җәйләрен исә коры һәм эссе була. Мондый һава шартлары күчеп килгән кешеләргә шактый кыенлыклар тудыра. Аларның күпчелеге җирле шартларга җайлаша алмыйча интегә.

Күченгән халык та әкренләп бу тирәлеккә, шартларга үзләшә, күнегә башлый: чыбыктан һәм балчыктан өй

төзү, камыштан паласлар, намазлыклар үрү, аны базарларда сату… Бу, аз гына булса да, гаиләгә ярдәм. Ә өй түбәсен кәздән – камыштан ясарга аларны төрек картлары өйрәтә. Соңрак алар терлек асрый, бодай, тары чәчә, бәрәңге утырта башлыйлар. Тормышлары акрын гына җайга салына. Бик авыр булуга карамастан, туган илләрен, үз җырларын, диннәрен онытмыйлар алар (хәзерге буын инде татарчаны начар белә, күбрәк төрек, инглиз, гарәп телләрендә аралаша).

Моннан 10–12 еллар элек авылга Төркиядән Гали исемле бер кеше кайта. Хәдичә апа Әхмәтовага үзенең өй макетын бүләк итә, Гали шул Әхмәтовлар нәселеннән булса кирәк, Хәдичә апа белән бик яхшы сөйләште (Хәдичә ханым истәлегеннән). Куак очында яшәгән 95 яшьлек Миңнегаян әбинең өенә кереп, хәлен сорашып, бүләкләр биреп калдыра (Әфләтунов Гатаның үги энисе).

Авылдан Төркиягә китүчеләр күп булган. Инде анда да өлкән буын вәкилләре сирәгәя бара, яшьләр исә авылны өлкән буын кешеләре сөйләве буенча гына беләләр икән. Аларның туган илне, авылны кайтып күрергә кушкан әманәтләрен үтәргә тырышалар.

Инде Төркиягә күченеп киткәннәр арасыннан бер гаиләнең нәселен тасвирларга тырышып карыйк. Ул нәсел кешеләре авылга кайтып киткәлиләр. Шуның өчен алар чагыштырмача ныграк танышлар.

Нәсел башы: **Кәлимулла белән Мәхүпьямал.**

Гариф – Кәлимулланың улы.

Маһирә – кызлары. Кияве – Фәсхетдин.

Гариф балаларының балалары (оныклары):

Хәнәфи – эшмәкәр, күп төрле транспорт чаралары, машиналары бар. Татарча төрек акценты белән сөйләшә.

Орыч – композитор, төрки телләр фольклорын җыя,

сәнгать профессоры. Татарча начар белә. Үзенең музыка мәктәбе бар. Орыч моннан 8–10 еллар элек кайтып, авыл мәдәният йортында концерт бирде. Төрекчә, казахча, үзбәкчә, татарча җырлар җырлады. Бер солистка татар җырларын башкарды. Орычның «Тумата» ансамбле чыгышын халык яратты. Җырчы Гөлтан татар халык җырларын башкарды. Орычның тагын ике бертуганы бар: Үсәр, Яшәр. Стамбул янәшәсендә Казлы авылы бар, Күперасты урамында Кәлимулла улы Гариф нәселе (оныклары) яши. (Бу мәгълүматларны Мәдинә Фәсхетдинова бирде. Ул берничә тапкыр Төркиягә барып, нәсел җепләрен өйрәнгән). Яхъя аганың бертуган апасы Хәдичә Фәсхетдинова (ире фамилиясе Гәрәева) Югары Чыршылыда гомер итә.

Алар, аларның нәселләре Стамбулда Босфор бугазының төньягында, Европа өлешендә яшиләр. Торган урыннары – 2-3әр катлы йортлар. Үзара күбрәк төрек, инглиз телләрендә аралашалар.

Нәсел бәйләнеше:

Яхъяның әтисе – Әхмәтзыя.

Әхмәтзыяның әтисе – Фәсхетдин.

Фәсхетдин хатыны – Маһирә (Яхъя – аларның оныгы).

Маһирә карчык, хәзрәттән сабак укып, Түбән Чыршылыга (Чәчелегә) барып, мәдрәсәдә имтихан тапшырган гыйлем карчык.

Яхъя нәселе:

Яхъя (1924). Рәисә (1925).

Аларның балалары:

Әнисә (1950). Сургут производство объектларының берсендә хисапчы булып эшләде.

Рәис (1952). Авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлады, тракторчы.

Мәдинә (1955). Лениногорск нефть техникумында укыды.

Халисә (1957). Лениногорск нефть техникумында белем алды. Техника куллану инженеры.

Әминә (1960). Нефть техникумын тәмамлап, буровойларда лаборант булып эшли.

Төркиягә барлыгы 34 гаилә күченеп китә.

Харис Усмановның бабасы Усман гаиләсе белән китә. Алар белән бергә Харисның бертуган апасы да киткән.

Хәтиф һәм Гатуф Хөснетдиновларның бабалары да гаиләләре белән күченгәннәр һ.б.

## Бөтендөнья бишенче татар конгрессы

Конгресс бергә булыйк, бердәм булыйк лозунгысы астында узды. Хәзерге чорга кагылышлы мәсәләләрне карады (милләтне, телне, гореф гадәтләрне саклау, яшь буынны милли рухта тәрбияләү).

2012 нче елның 6 – 9 нче декаберендә Казан шәһәрендә Бөтендөнья татарларының V конгрессы булып узды. Бу конгресска бөтен дөньядан 794 делегат катнашкан. Конгресс хәзерге чорга кагылышлы актуаль мәсьәләләрне караган. Делегатлар арасында Төркия татарлары вәкилләре дә катнашкан. Алар арасында борынгы Әби авылы нәселләре кешеләре дә булган. Үзләренең нәсел буыннары яшәгән авылны күрү өчен, Сарабикколга килделәр. Авылда аларны авыл советы рәисе (Муниципаль берәмлек рәисе) Гүзәл Рәис кызы Адельщина, Лениногорск мәдәният йорты вәкиле Сәрия Ашрапова, авылдан Гарифуллина Галия, авыл тарихы материалларын җыючы Рәшит Кыяметдин улы Якуповлар озата бырдылар. Төрек татарлары Абдуллаһ Атасевер – эшмәкәр, 3 – 4

Сәнәкчеләр Совет хөкүмәтенә теләктәшлек белдергән һәркемне үтергәннәр. Сарабикколның беренче укытучыларыннан берсе Юныс Мингазиевны тотып алып, каты кыйнап, авыл бае Хәниф Исмәгыйлев келәтенә ябалар. Ул келәттән ничектер качып чыга. Сәлах Кашапов һәм Гата Гыйбадуллиннарда яшеренеп кала. Иштирәк авылыннан килеп укытучы Шәфыйк аганы да кулга алалар һәм Куак авылында җәзалап үтерәләр. Бәркәтәдән килеп укытучы Таһир мулланың ике кызын да шундый язмыш көтә. Аларны Куакбашка илтеп тапшыручы — Хәертдин Хәкимов. Аны бу эшкә сәнәкчеләр мәҗбүр итәләр. Сәнәкчеләр тарафыннан җәберләп үтерелгән Корчагин һәм башкалар авылда, тирә-якта күп була. Соңгы чиктә сәнәкчеләр Салашник станциясен алу өчен шунда юнәләләр. Ләкин Антонин авылы янында Кызыл Армия тарафыннан тар-мар ителәләр. Сәнәкчеләрнең алда телгә алынганнары үзләренә тиешле җәзаны алалар.

(Бу материалның бер өлеше эзтабарларның авыл буенча йөреп җыйган тупланмасыннан алынды. Эзтабарлар җитәкчесе – Шакир Шәйхелислам улы Фәйрүзов. 1970 ел).

## Комиссар Корчагин урамы

1920–1921 елларда Урта Иделдә ачлык хакимлек итә. Бөгелмә өязеннән безнең якларга ике вәкил җибәрелә: аларның берсе – Корчагин (ашлык хәзерләү оешмасы әгъзасы) Сарабикколга килә, икенчесе – Бушуев – Куакта кала. Совнарком күрсәтмәсе буенча, бу вәкилләр икмәк хәзерләүне оештырырга тиеш булганнар. Аларның килүе сәнәкчеләр күтәрелгән чорга туры килә. Ач, ярсыган халык икмәк җыючыларны күрергә дә өлгерми, сәнәкчеләр-

тендә, Сарыйм байның зур өендә, Шаһи Хаҗи келәтендә) тукландыру ашханәләре оештырылган. Көнгә бер мәртәбә Америка паегыннан хәзерләнгән аш ашатканнар, киеме булмаганнарга аяк һәм өс киемнәре биргәннәр.

1922 ел исән калган авыл һәм тирә-як халкы өчен бәхет елы булган. Күптән зарыгып көткән көнбатыш җилләре җылы һәм дымлы һава алып килгән. Табигать уянган, чәчелгән игеннәр мул булып үскән һәм өлгергән. Халык иркен сулыш алган. Ләкин 1921 ел күрсәткән кытлык авыл тарихына тирән кереп калган. Өлкән буын бу кытлык турында хәзерге буынга гыйбрәт итеп искәртеп тора, икмәкнең һәм табигать байлыкларының кадерен белергә кирәклек турында даими аңлата. Андый куркыныч кытлык елларны хәзерге һәм киләчәк буыннарга күрергә, кичерергә язмасын дип, дога кыла.

## Сәнәкчеләр

Халык телендә «бәла-каза һәм бәхетсезлек ялгыз йөрми» дигән әйтем бар. Хактыр. 1920–1921 еллардагы ачлык-кытлыклар белән янәшә «сәнәкчеләр хәрәкәте» барлыкка килгән. Бу еллардагы кыенлыкларны кайбер шәхесләр, төркемнәр хөкүмәткә каршы чыгу өчен файдаланган. Ачтан, тормыш кыенлыкларыннан интеккән халык сәнәкчеләр хәйләсенә эләккән, сәнәкчеләргә ияргән.

Сәнәкчеләрнең оешкан төп авыллары: Сәет Кирлегәче, Сарабиккол, Чәчеле, Куакбаш. Оештыручылары Сәет Кирлегәченнән булган дигән фаразлар бар. Авылдан сәнәкчеләргә теләктәшлек белдерүчеләрнең кайберләре: Әбүзәр Сәхипов, Кәрәм Усманов, Миңнебай Вилданов, көтүче Галим, Гыйләҗ Хөснетдинов, Ямалетдин Ногманов (Куак очы мәчете хәзрәте).



гә иярә. Сәнәкчеләр башлыгы Кирлегәч авылы кешесе була. Алар Корчагинны яшеренгән урыныннан табып алып, кара канга батырып кыйныйлар. Кышкы ачы салкында яланаяк килеш Шушма күпере баганасына бәйләп куялар. Корчагинның интеккәнен карарга дип, бөтен авыл халкын куып китерәләр. Ә сәнәкчеләр үзләре кәеф-сафа корырга китә. Китәр алдыннан: «Корчагинга якын килеп, аңа кул белән кагылган кешене шунда ук тотып атабыз!» – дип, кисәтеп куялар.

Төн җитү белән Ситдыйк карт (Гаҗилә Ситдыйкованың каенатасы) аны чишеп, үзенең мунчасына яшерә. Әмма сәнәкчеләр Корчагинны кан эзе буенча килеп табалар, урамга алып чыгып, атып үтерәләр. Аннары гәүдәсен Сарабиккол урманы буена илтеп күмәләр. Соңыннан гәүдәсен кире казып алып, Кирлегәч белән Сарабиккол авыллары арасындагы ком базына илтеп күмәләр. Моны гаеп Кирлегәч халкына да төшсен өчен шулай эшлиләр. Шуннан соң «продотряд», берничә сәнәкчедән күмелгән

кабереннән кире казытып алып, Корчагинның гәүдәсен Куак авылына озата. Куак кешеләре Корчагинны, Бушуевны һәм Ждановны хөрмәтләп, чиркәү кырыена зурлап җирли. Хәзер ул урында бер кечкенә генә һәйкәл тора.

Корчагин атылган урам, аның исемен мәңгеләштерү йөзеннән, Корчагин урамы дип йөртелә башлый. Бу урам — тарихи урам, ул күп үзгәрешләр дә кичергән, монда тарихи вакыйгаларны үз күзләре белән күргән шаһитлар да яшәгән. Менә аларның кайберләре:

**1. Ялалетдин Гыйлалов, хатыны Гайшә.** Балалары: Гаҗилә (ире Фатыйх, балалары: Габдулла, Әсхәт); Хаҗия (Тукмакта), Наҗия (укытучы булып эшләде, Казанда вафат булды); Җария (техничка); Гөлия (укытучы); Таҗетдин (1930 елгы, Бөгелмә шәһәренең тимерьюлчылар мәктәбен тәмамлады, машинист ярдәмчесе булып эшләде. Әтисенең иске дүртпочмаклы өе урынына алты почмаклы йорт салды, ләкин үзе Бөгелмәдә тормыш корганлыктан, йортны өлкән апасы Гаҗиләгә калдырды).

Ялалетдин карт гомер буена колхозда эшләде. Кайчак вак-төяк сату эшләре белән дә шөгыльләнде. Ул әкиятләр сөйләргә бик ярата иде. Шундый бер сөйләшү вакытында Әкъдәс Мостафин аннан: «Бабай, сине нигә Әкрен Ялак дип йөртәләр?» – дип сораган. Ялалетдин карт тыныч кына: «Тихонько булганга», – дип җавап биргән. Шуннан соң балалар аны «Әкрен бабай» дип йөртә башладылар.

Хатыны Гайшә апа гомере буе колхоз ашханәсендә аш пешерүче булып эшләде.

**2. Нуретдин Ялаков, хатыны Гыйлемзадә.** Балалары: Нургаен (хатыны Камал), Фатих (хатыны Зәйнәп), Хәниф (хатыны Зәкия, шәфкать туташы), Хәсән (сугышта югалды), Хөсәен (хатыны Әкълимә). Хөсәен төзүче бул-

ган, өйләре дүрт почмаклы, өй алды такта-киртә, саламнан оештырылган, бер баш атлары булган.

Хуҗа үзе һәм балалары кирпеч сугу белән шөгыльләнәләр иде. Сугыш елларында бик зур кыенлыклар кичерделәр: утын юклык, ачлык һ.б.

**3. Әюп Низамов.** Беренче хатыны Әсма, икенчесе Нәсимә (Чыршылыдан) булган. Балалары: Мөкәррәмә (Урта Азия якларында яшәде), Кәримә (Чыршылыда яшәде), Зәйнәп (шулай ук Чыршылыда гомер итте), Шакир (сугышта югалды), Хәтирә (апасы янында Урта Азиядә яшәде).

Әюп бабайның йорты дүрт почмаклы иде, үзенең мунчасы да булган. Үзе гомер буе мәктәптә ат караучы булып эшләде, завхоз вазыйфаларын да башкарды.

**4. Җәләлетдин улы Якуп** (1847–1922), **карчыгы Сәрбиҗамал** (1842– 1917). Якупның төп һөнәре – иген игү һәм терлек асрау. Аннары ул, Чистай шәһәренә барып, калайчы эшенә дә өйрәнеп кайта. Авылда калай әйберләр (чиләк, таз, чүмеч, комган, самовар һ.б.) ясый һәм аларны ремонтлый. Бу кәсебе аңа өстәмә табыш-керем китерә, тормышлары мул, иркен була. Якупларның йортлары сигез почмаклы иде. Чәчүлек җирләре дә күп, 4 баш аты, 6 баш сыер терлеге, сарыклар, кош-корт асраганнар. Бик яхшы итеп эшләнгән таш йорт, таш келәт, таш коймa белән әйләндереп алынган мал абзары булган. Соңгы елларда бу йортның бер башында Кыяметдин, икенче башында Сәхабетдин (Якупның уллары) яшәгән. Алар авыл халкы өчен сепарат тотканнар.

Якуп карт кырыс холыклы, үзсүзле һәм тәвәккәл кеше булган. Гарәпчә укый-яза белгән. Балалары: Миңкәбану (1868–1949), ире – Якуб, Ялтау кешесе, Гөлмикамал (1870–1962), ире Хәмәтгали, Ялтау кешесе, Сәхабетдин

(1872–1954), Сәмига (1886–1954), Кыяметдин (1888–1957), Минхәят (1882–1949).

Болардан тыш, Корчагин урамында тагын башка бик күп кызыклы һәм гыйбрәтле шәхесләр яшәгән: Юныс Дусаев – авыл бае, берничә тапкыр Согуд Гарәбстанының Мәккә шәһәренә хаҗга барып кайта, шуннан соң аны Юныс хаҗи дип йөртә башлыйлар. Корчагин урамындагы иң матур йорт-корылмалар аныкы: киселгән таштан салынган өч бүлмәле бина урамга карап торган. Бүлмәләрнең берсе кибет ролен үтәгән, икенчесе – склад, өченчесе – уртадагысы – кунаклар кабул итү урыны булып хезмәт иткән. Юныс байның су тегермәне (Ташкичү тегермәне) , кибете һәм умарталыгы булган. (Хәзер ул умарталык колхозныкы). Моннан тыш ул күп санда атлар, сыерлар, кош-корт асраган. Ул гади кешеләргә карата бик мәрхәмәтле булган, дүрт хезмәтчесе булуга карамастан, ул ашларны алар белән бергә утырып ашаган, ярлыябагайларны беркайчан да кире борып чыгармаган, аларга бурычка да әйберне, акчаны кызганмый биреп торган. «Юмарт Юныс» кушаматы аның әнә шуннан калган.

Юныс тегермәне Ташкичү астында Мукшы елгасында эшләгән, ул авылда бердәнбер тегермән булган. Безнең якларны өйрәнгән галим-этнограф С.Паллас нәкъ менә шушы тегермән турында язып калдырган да инде.

Хәзерге колхоз умарталыгы урынында Юныс байның, Кыяметдиннең һәм Сәхабетдинның умарталыгы булган. Юныс ишле гаилә башлыгы була, улларының исемнәре: Хәмәтзыя, Шакир, Закир (Бөек Ватан сугышында үлеп кала), Хафиз, Фатих (шулай ук Бөек Ватан сугышында һәлак була).

1920–1930 елларда бу зур гаилә таркала. Ә Юныс бай «кулак» исеме астында авылдан куыла. Шулай да

бу шәхес һәм аның балалары Совет власте урнаштыру елларында илнең икътисадын күтәрүгә үзләреннән зур өлеш керткәннәр, Ватанны фашистлардан саклап та көрәшкәннәр.

Башка шәхесләрдән: тегермәнче Мортаза; хәлфә Талыйп (Садыйков); күмәчче Харрис Усманов; милешче (мелочник) Шәйхетдин; мәэзин Хәсәнша (Галимов – ул Ямалетдин мәчетеннән азан әйтүче булган, ике хатынга өйләнгән, беренчесе – Хәнифә, балалары: Миндинә, Мәрьям, Идрис һәм Асия; икенче хатыны – Мөршидә, балалары: Минхәт, Рәфкать, Мөнир); Һади Авширов (авыл Советы рәисе булган); Гариф Гайсин (сельпо хисапчысы). Бу кешеләр һәммәсе дә үзләре өчен генә түгел башка кешеләрне дә кайгыртып яшәгәннәр, эшләгәннәр. Аларның исемнәре, язмышлары елдан-ел ерагая, безнең өчен тоныклана бара. Истәлекләре дә шулай. Алар арасында Корчагин белән булган хәлләрнең тере шаһитлары да булгандыр. Чынлыкта, Якупов Кыяметдин тыкрыгында ату тавышын ишетүчеләр булган бит, әмма өйләреннән чыгып карарга гына курыкканнар…

,

әдәбият укытучысы, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп билгеләнә. 1990 елдан мәктәп директоры вазифаларын уңышлы башкара. 2005 елда «Россия Федерациясенең почетлы мәгариф хезмәткәре» исеменә лаек булды.

Аның җитәкчелегендә эшләүче укытучылар: Асия Исхакова – мәктәпнең укыту-тәрбия бирү бүлеге мөдире (завуч), Асия Локманова, Рәйсә Сөнгатуллина, Нурзия Садыйкова, Гөлчәчәк Моталлапова, Сәлимә Гатина, Фәния Ихсанова, Фәния Ялакова, Галия Мусина, Роза Сафина, Энҗе Камалетдинова, Фәния Әскарова, Әлфинур Бәдгытдинова, Тәнзилә Дәүләтшина, Рәсинә Минһаҗева.

### *Балалар йорты (Детдом № 100)*

Бөек Ватан сугышы афәтләре Сарабиккол авылын да читләтеп үтми. Безнең авылдан да, тирә-юнь авыллардан да күп кеше Ватанын якларга яу кырына китә.

1942–1943 еллар – Бөек Ватан сугышының иң кызган чоры. Фашистлар Германиясенә каршы сугышта һәлак булганнарның саны артканнан-арта бара, ятим калган балалар да күбәя. Аларны тәрбияләү-укыту өчен Сарабикколда балалар йорты ачыла. Анда 150 ятим бала тәрбияләнә.

**100нче номерлы Сарабиккол балалар йорты пионер оешмасы кече төркеме. Вожатые Гөлсем Насибуллина. Рамка эчендә Луиз Хафизов Сәет улы.**





Сарабиккол балалар йортында эшләүче тәрбиячеләр коллективы. 1944 ел.

Балалар йорты (детдом) өчен бар көчен һәм сабырлыкларын салган кешеләр бик күп, аларның һәркайсысына аерым рәхмәт! Балалар тәрбияләү – ифрат авыр эш, ә ятим баланы аякка бастыру тагын да күбрәк көч, тырышлык һәм түземлелек таләп итә. Шундый гаять зур һәм игелекле хезмәтне башкарган кешеләр менә алар кемнәр:

Мәгъмүрә Хафизова – балалар йортының беренче директоры;

Гата Вәлиуллин – ярдәмче хуҗалыкны оештырды;

Сарабиккол балалар йорты китапханәсендә эшләп килгән әдәби түгәрәк әгъзалары. Түгәрәк җитәкчесе Г.Г.Якупова. 1960–1961 еллар.



Фәхразый Авширов – хуҗалык бүлеге мөдире;

Миргасыйм Зәйдуллин – яңа бина салдырды, аңа кадәр балалар ис-

ке мәктәп һәм мәчет биналарында яшәгәннәр;

Суфия Әхмәтова – укыту бүлеге мөдире;

Мушаков – директор;

Мөкатдәс Шәрәпов – директор;

Рәшит Якупов – укыту бүлеге мөдире;

Таһир Миндаров – директор;

Тәрбиячеләр: Рәшидә Усманова, Разыя Усманова, Заһидә Корбанова, Рәисә Якупова, Мөнәвәрә Баһаветдинова, Зифа Исхакова, Асия Гыйлалова, Гөлсирин Якупова, Кәшифә Кәримова, Фәүзия Хәкимова, Һаҗәр Димеева, Гөлсем Насыйбуллина һ.б.

Алардан тыш балалар йортында тагын күп кенә башка һөнәр ияләре дә эшләгән: Ольга Федоровна Коршина – шәфкать туташы, Камал Әхмәтова – кер юучы, Анна Карпова – умартачы, Порфирий Степанов – столяр һәм укытучы, Фатиха Гарипова – тегүче, Хөсәен Әскаров – хисапчы, Кәримә Гыйләҗева – бала караучы-җыештыручы, Фатыйма Насыйбуллина – хисапчы, төнге тәрбияче, Камал Сарыймова – бала караучы-җыештыручы, Рәфкать Мортазин – хисапчы, Әнисә – пионервожатый, Минзадә Назыйрова – техничка.

1961 елда балалар йорты Бөгелмә шәһәренең икенче интернат-мәктәбенә күченде, ә элекке балалар йорты бинасында махсус мәктәп ачылды.

## Авылның демографик хәле

Демографик хәлне авыл мәктәбе ачык күрсәтә. Шуңа да сүзне мәктәптән башлыйк. Сарабикkол урта мәктәбе күп еллар буена районда алдынгы урыннарны алып килә. Мәктәпнең эчке һәм тышкы күренеше заман таләбенә туры килә, зәвыклы. Укытучылар коллективы бердәм, мәктәп тиешле кадрлар белән тәэмин ителгән. Мәктәпнең матди һәм методик базасы нык. Ләкин укытучылар коллективын елдан-ел балалар саны кимү борчый. Алдагы елларда ул сан ничек булыр? Берничә елгы мәктәпнең перспектив планын карап үтик.

| **Еллар** | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәктәптә балалар саны | 95 | 95 | 93 | 90 | 57 | 50 | 46 |
| Беренче сыйныфка керүчеләр саны | 13 | 8 | 6 | 5 | 5 | 4 | 6 |

Бу саннар авылның картаюы турында сөйли кебек. Демографик хәл, бөтен Рәсәйдәге кебек, Сарабикколда да халыкның саны кимүгә таба баруын күрсәтә. «Ана капиталы» турындагы һәм яшь балаларга пособиеләрне арттыру турындагы законнар авылдагы демографик хәлнең яхшыруына китерер бәлки. Бу елда үзгәреш күренми. 2009 елда авылда туган балалар саны – 5. Үлүчеләр – 35.

Авылда балалар санының кимү сәбәпләре: илдәге кыйммәтчелек, алдагы көнгә, елга ышаныч булмау, әти-әниләрнең даими ышанычлы эш урыннары юклык, медицина һәм мәгариф учреждениеләренең түләүле булуы, эш хакының гаять түбәнлеге, төрле түләү бәяләренең артуы

(газ, электр энергиясе, юл, салымнар һәм башкалар).

Баланы мәктәпкә әзерләү эти-әниләргә елына якынча – 4–6, югары уку йортларында укыту 18–50 меңгә төшә. Моны барлык гаиләләр дә түли алмый (гәрчә бай гаиләләр өчен бу зур сумма булмаса да). Күпчелек халыкка заманаларның уңай якка үзгәрүен көтәргә кала.

## Бүгенге авылның демографик хәле – саннарда

| Еллар | Туган | Вафат |
|---|---|---|
| *1997* | *7* | *12* |
| *1998* | *8* | *12* |
| *1999* | *5* | *19* |
| *2000* | *5* | *17* |
| *2001* | *6* | *24* |
| *2002* | *4* | *25* |
| *2003* | *5* | *26* |
| *2004* | *4* | *18* |
| *2005* | *7* | *17* |
| *2006* | *8* | *13* |
| *2007* | *7* | *24* |
| *2008* | *7* | *18* |
| *2009* | *1* | *29+5 читтән - 34* |
| *2010* | *3* | *18* |
| *2011* | *6* | *13* |
| *2012* | *6* | *17+5 читтән - 22* |
| *2013* | *1* | *8+1 читтән - 9* |

Бу мәгълүматлар медицина пунктыннан һәм теркәп баручы Әхтәм Барый улы Сарыймовтан алынды.

**2010 елның 14–25 октябрендә Сарабиккол авылында җан исәбен алу (перепись) нәтиҗәләре.**

Авылда 296 йорт исәпләнә. Шуның 254ендә кешеләр яши. 42 йортта – вакытлыча яшиләр, күбрәк – җәй айларында, аларны «дачниклар» дип атыйлар.

Переписьта исәпкә алынган кешеләр саны – 689. Шулардан: ир-атлар – 322, хатын-кызлар – 367.

Авыл әкренләп картая. 180 кеше лаеклы ялда. Шуларның 55е – ир-ат, 125е – хатын-кызлар.

Авылда укый-яза белмәүчеләр юк.

Авыл мәктәбендә 46 бала укый. Балалар бакчасында 22 бала тәрбияләнә. Өй шартларында гына яшәүчеләр – 13 бала.

Халык саны исәбен алучылар: Миләүшә Мансур кызы Сафина – инструктор; Назилә Наил кызы Хәбибуллина белән Лилия Хәмзә кызы Камалетдинова – переписчиклар.

Авылда 310 йорт исәпләнә.

270 ендә кешеләр яши.

2013 елның 1 мартына авылда 657 кеше яши.

42 йортта кешеләр вакытлыча (җәй айларында) яшиләр.

Переписта алынган кеше саны 689.

Ир-атлар - 322.

Хатын-кызлар - 367.

Лаеклы ялда - 180. Шуларның 55 - ир-ат.

125 - хатын-кыз.

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК



# Җиде буын җепләре

*Иң зур ямьсезлек – рухи гамьсезлек.*
*Гамьсез булмыйк,*
*карыйк әле тамырларыбызга,*
*өйрәник, белик әле, чын тарихыбызны*
*җиткерик әле киләчәк буыннарга.*

Чал тарихлы, гүзәл һәм бай бу төбәккә язмышның аяусыз җилләре халыкларны төрле яклардан үзенә җыйган. Элек Биккулово исемен йөрткән бу авылга төп халыклар көнбатыштан, «ак яктан», мәгърифәтле яктан, ислам дине нык үтеп кергән яктан килгәннәр (качып килгәннәр дисәк, тагын да урынлырак булыр). Чын татар телендә сөйләшүче типтәр-бабуллар булганнар (җирсез ярлылар). Авылның оешуы, барлыкка килүе турында берничә гыйбарә бар. Шуларның берсе: көнчыгыштан бу территориягә бер хатын-кыз килеп, Каенлы чишмә янында туктала. Соңрак шул хатынның гаиләсе дә килә. Бу чишмәне хәзер Изгеләр чишмәсе дип йөртәләр. Әлеге сүзләргә игътибар итсәк, авыл көнчыгыш яктан төзелә башлаган булырга тиеш.

Авылның төзелә башлау урынын каберлекләр ачыклый. 1965–1966 елларда авылга Казан фәннәр академиясеннән галим-археолог Альфред Халиков килде. Авылның көнбатышындагы каберлеге борынгырак икәнлеге ачыкланды. Димәк, авыл көнбатыштан төзелә башлаган. Шул ук фикерне Хәтиф Мостафин, Мәхмүҗан Шаһиева, Зәйнәп Ялакова да раслады.

1746 елга кадәр Биккулово авылы патша чиновникларына билгеле булмый. Авыл халкы, ясак һәм салым түләүне белмичә, мул тормышта яшәгән. Бу халык билгеле бер тәртип белән көн күргән. Аксакаллар тәртибе катгый

булган: җир кишәрлекләре дисәтинәләп бүленгән (5 дисәтинә 4,5 гектарга тигез), печәнлекләрдән кипкән печәнне чүмәләләп бүлгәннәр (бер гаиләгә 30–40 чүмәлә тиеш булган) һәм башка шундый тәртипләр урын алган.

Халыкның бу якка күчеп килү сәбәпләре уртак, охшаш. Менә ул сәбәпләр:

1. Салым түләү авыр булган. Һәр төтен чыга торган морҗа башына 25 тиеннән акча налогы түләгәннәр. Бу чор өчен әлеге сумма – гаять зур сумма. Соңрак салым гаилә әгъзалары санына карап түләнгән. Монысы исә тагын да авыррак инде.

2. Сөрү җирләренең яхшылары бай катлам, чиновниклар, дин башлыклары кулында булу сәбәпле, гади халыкка уңдырышсыз җирләр генә калган.

3. 1713–1764 елларда патша хөкүмәтенең рус булмаган халыкларны бер калыпка берләштерү (руслаштыру) сәясәте алып баруы. Шундый сәбәпләр нәтиҗәсендә Казан арты, Чаллы төбәге халыкларының бер өлеше аулак якларга качып китәргә мәҗбүр була.

Шул чорда Рәсәйдәге сәяси һәм икъдисадый хәлләр кешеләрне төрле юнәлешләрдә хәрәкәт итәргә этәргән. Шундый күченү төркемнәре көнчыгыштан көнбатышка таба да барган. Бу халыкларның күпчелеген башкортлар тәшкил иткән. Әлеге хәрәкәт агымында Мирзагол кабиләсе дә булган дип фаразлана.

### Мирзагол нәселе

Сарабиккол авылының тарихы башкорт яклары белән бәйле. Элек хәзерге Башкортстанның көньяк-көнбатыш өлешенең бик зур мәйданын Мин өлкәсе алып торган. Ул 11 волостьны берләштергән (бу бүленеш еш кына үзгәреп торган). Бүленеш патша Алексей Михайлович Указы бе-

# *Мирзагол нәселенең кыскартылган шәҗәрәсе*

**Мирзагол**

- **Миңлехәер**
  - **Миңлегалим**
- **Якуб (1720–?)**
  - **Карабай (1745–1805)**
    - **Фәйрүз (1800–?)**
      - **Фәрхетдин (1825–1900) 1 хатыны, баласы,**
        - **Камалетдин (1847–?) 2 хатыны, баласы,**
        - **Габделвәли,**
        - **Җамалетдин (1832–?) 1 хатыны, баласы,**
        - **Сәлахетдин (1871–?),**
        - **Нуретдин (1864–?) 3 хатыны, баласы,**
          - **Сәхабетдин (1869–?).**
          - **Шәйхлислам → Мәсхүдә, Шакир, Сәгыйть, Әминә**
            - **Шакир → Рим, Римма, Әлфия, Роза, Шакирә.**
            - **Сәгыйть → Рафаэль, Равил, Резеда.**
            - **Әминә → Урал, Ирина.**
- **Бикқол (1725–?) + Сара**
  - **Сәлим Сарабиккулов (1750–1814)**
    - **Шәмсетдин (1773–?) 3 хатыны, 8 улы**
      - **Җәләлетдин (1802–?) 1 хатыны, баласы**
      - **Хәбибулла (1811–1871) 1 хатыны, баласы**
      - **Ибраһим (1814–1830) 1 хатыны, баласы**
      - **Җамалетдин (1815–1830) 1 хатыны, баласы**
      - **Йосыф (1815–?) 2 хатыны, баласы**
      - **Мостафа (1817–?) 2 хатыны, баласы**
      - **Мортаза (1820–1859) 2 хатыны, баласы**
      - **Әхмәтҗан (1825–?) 3 хатыны, баласы**
      - **Якуб → Кыяметдин**
        - **Кыяметдин → Дөрлиҗинан, Хәнәфия, Шамил, Габдерәкыйп, Миншакир, Якутелҗинан, Рәшит.**
    - **Габделвахит (1800–1820)**

лән 1646 елда расланган. Шулай булуга карамастан, башкорт халкы арасында җир бүленешенә бәйле ызгышлар дәвам иткән.

